**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2019-2020 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 38**

**I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл). Биремнәргә бер сүз һәм сүзтезмә белән җавап бирегез.**

1. Әдәби әсәрдә персонажның эчке дөньясын, хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын җентекләп сурәтләү. **Психологизм**
2. Әсәрдә геройларның үзара каршылыкка керүе. **Конфликт**
3. Әсәрдә табигать күренешләренең сурәтләнеше. **Пейзаж**
4. Вакыйгалар хис-кичерешләр белән үрелеп барган лиро-эпик жанр. **Поэма**
5. Аерым бер иҗтимагый катлауны борчыган, аларга хас хис-тойгылар гәүдәләндерелгән шигырьләр. **Гражданлык лирикасы**
6. Кече, катлаулы булмаган вакыйганы, кешенең билгеле бер сыйфатын ача торган эпик жанр. **Хикәя**

**II. Әдәби әсәргә караган биремнәр (16 балл).**

1. Бу өзек кайсы әсәрдән? **“Мокамай”**

*Менгән саен җирнең матурлыгын,*
*Яктылыгын күбрәк күралдым...*
*Ә син меналмадың...*
*Калдың,*
*Югалдың...* (2 балл).

2. Бу әсәр кем тарафыннан иҗат ителгән? (2 балл). **Һ.Такташ**

3. Бу әсәрнең лирик героена бәя бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? Лирик геройның дустына мөнәсәбәте нинди? (6 балл). **Ул чын күңелдән дустын ярата, аның өчен борчыла, аның гомерен саклап кала алмаганы өчен газаплана, үкенә, аның фаҗигале язмышы өчен сызлана һ.б.**

4. Лирик герой күңелендәге эчке каршылык нинди вакыйгага бәйле туа? Ул ни өчен сызлана? (6 балл). **Лирик герой күңелендәге эчке каршылык Мокамайның үлеменә бәйле туа. Ул Мокамайның тормышта үз урынына таба алмаганы өчен, матур эшләр эшли алмыйча киткәне, әкияттәге кебек матур башланган тормышын фаҗигале үлем белән төгәлләве өчен сызлана.**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2019-2020 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 46**

**III. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (16 балл). Биремнәргә бер сүз һәм сүзтезмә белән җавап бирегез.**

7. Фәлсәфи, дидактик фикер белән сугарылган, кыскалыкны, фикер тыгызлыгын таләп итә торган лирик шигырь. **Кыйтга**

8. Әсәрдә үткәрелгән төп фикер. **Идея**

9. Яшәүнең мәгънәсен эзләүче ялгыз шәхес фаҗигасен үзәккә куйган агым. **Сызлану фәлсәфәсе**

10. Әдәбиятның хис-кичерешләрне белдерүгә корылган төре. **Лирика**

11. Лирик әсәрдә төп герой. **Лирик герой**

12. Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен, йөз төзелешен, буй-сынын, сөйләмен тасвирлау. **Портрет**

13. Эпик төрнең хикәядән зуррак булган, вакыйгалар киңрәк планда бирелгән жанры. **Повесть**

14. Әдәби әсәрдә өлешләрнең урнашу тәртибе. **Композиция**

**IV. Әдәби әсәргә караган биремнәр (20 балл).**

2. Бу өзек кайсы әсәрдән? **"Тапшырылмаган хатлар"**

*Нинди матур истәлек! Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да синң, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә* (2 балл).

2. Бу әсәр кем тарафыннан, кайчан иҗат ителгән? (3 балл). **Гадел Кутуй тарафыннан 1935 нче елда иҗат ителгән.**

3. Бу әсәрнең төп героена бәя бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (5 балл). **Төп герой – Галия. Ул чын күңелдән ярата белә, матур гаилә төзергә хыяллана, балаларын, тормышны ярата, үз эшенә бирелгән, тормыш сынаулары аны ныгыта һ.б.**

4. Әсәрдә төп тышкы конфликт кемнәр арасында, ни сәбәпле туа? Ул ничек чишелә? (5 балл). **Әсәрдә төп тышкы конфликт Галия белән Искәндәр арасында туа. Алар мәхәббәткә, гаиләгә карата төрле фикердәге кешеләр булып чыга, гаилә сакланып кала алмый. Конфликт гаиләнең таркалуы белән чишелә.**

5. Әсәрдә автор нинди проблемалар күтәрә? (5 балл). **Әсәрдә сурәтләнгән күпсанлы вакыйгаларда мәхәббәт, гаилә бөтенлеге, гаиләгә мөнәсәбәт, балалар каршындагы җавапсызлык, тормыш авырлыкларына җиңел карау, әхлаксызлык, хезмәткә мөнәсәбәт һ.б. проблемалар күтәрелә.**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2019-2020 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 46**

**V. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (16 балл). Биремнәргә бер сүз һәм сүзтезмә белән җавап бирегез.**

15. Персонажларның трагик каршылыгына нигезләнгән, фаҗига белән тәмамлана торган драматик жанр. **Трагедия**

16. Әсәрдә күтәрелгән төп мәсьәлә. **Проблема**

17. Суфичылык күренешенең үзенчәлекле алым-чаралар аша әдәбиятта чагылышы. **Суфичылык әдәбияты**

**18.** Тормышны төрле яклап күрсәтүче, еш кына кеше, аның язмышы, аңа бәйле вакыйгалар турында детальләп хикәяләүче әдәби төр. **Эпос, проза**

19. Мәгърифәтчелек фәлсәфәсенә нигезләнеп, чынбарлыкны акыл, белем, тәрбия төшенчәләре аша чагылдырган әдәби агым. **Мәгърифәтчелек реализмы**

20. Чынбарлыкны сүз ярдәмендә чагылдыра торган сәнгать төре. **Матур әдәбият**

21. Эпик төрнең повестьтан зуррак булган, вакыйгалар киң планда бирелгән жанры. **Роман**

22. Әдәби әсәрдә вакыйга-хәлләрнең, кеше холкының үсү-үзгәрү тарихы. **Сюжет**

**VI. Әдәби әсәргә караган биремнәр (20 балл).**

3. Бу өзек кайсы әсәрдән? **“Сагыну”**

*Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.* (2 балл).

2. Бу әсәр кем тарафыннан, әдәбиятның кайсы чорында иҗат ителгән? (3 балл). **Г.Кутуй тарафыннан сугыш чорында языла.**

3. Бу әсәрнең төп героена бәя бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (5 балл). **Бу әсәрнең төп герое – солдат. Ул үзенең илен сагына, чит илдә ямь таба алмый, матурлыкны күрми, иле турында уйлау гына да аңа көч-дәрт бирә, ата-бабалар рухы турында уйлый һ.б.**

4. Әсәрдә геройның эчке каршылыгы ни сәбәпле туа? Ул чишеләме? (5 балл). **Ул чит илдә үзенә күңел тынычлыгы таба алмый, аны җиңүче итеп каршыласалар да, күңеле еракта. Ул үз күңелендәге каршылыкны кайтуына ышанып җиңә. “Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем”, ди.**

5. Әсәрдә татар халык җырларыннан өзекләр нигә кертелгән дип уйлыйсыз? Алар нинди вазифа башкара? (5 балл). **Ул ата-бабалары корган изге йорты турында уйлый, җырлар аның күңелендәге ачуны һәм сагынуны җиткерү өчен кулланыла һ.б.**

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2019-2020 уку елы) 10 нчы сыйныф

**Максималь балл – 50**

**VII. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (20 балл). Биремнәргә бер сүз һәм сүзтезмә белән җавап бирегез.**

23. Әдәби әсәрдә кешенең эчке һәм тышкы бербөтен сурәте. **Образ**

24. Нинди дә булса күренешне яки предметны аңлатучы шартлы сүз яки билге. **Символ**

25. Шигъри әсәрдә үзенең эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын нәфислек белән, укучының күңеленә үтеп кererлек итеп бәян итүче образ. **Лирик герой**

26. Әдәбиятта көлүнең бер төре, усал һәм ачы итеп көлүне аңлата. **Сатира**

27. Чынбарлык вакыйгаларын сурәтләү аша аның нигезләрен тәнкыйтьләүгә йөз тоткан әдәби агым. **Тәнкыйди реализм**

28. Билгеле бер идеал яктылыгында тормышны үзгәртеп тасвирлауга нигезләнгән иҗат юнәлеше. **Романтизм**

29. Тормыш-яшәешне яңача, яңа әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи кыйммәтләр яссылыгында чагылдыручы, татар әдәбиятында XX йөз башында урын алган иҗат юнәлеше. **Модернизм**

30. Әдәби әсәрдә әсәр өлешләренең урнашу тәртибе. **Композиция**

31. Әдәби әсәрдә ике геройның кара-каршы сөйләшүе. **Диалог**

32. Тормыш-көнкүрештәге, аерым кешеләр холкындагы кимчелекле яклардан көлүгә нигезләнгән драма жанры. **Комедия**

**VIII. Әдәби әсәргә караган биремнәр (20 балл).**

4. Бу өзек кайсы әсәрдән? **“Сөннәтче бабай”**

*Аның яшен белгән кеше юк иде. Яше күпме дип уйлаган кеше дә юк иде... Аның, яше югалган кеби, исеме дә югалган иде...* (2 балл).

2. Бу әсәр кем тарафыннан, әдәбиятның кайсы чорында иҗат ителгән? (3 балл). **Гаяз Исхакый тарафыннан XX йөз башында иҗат ителгән.**

3. Бу әсәрнең төп героена бәя бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (5 балл). **Төп герое – Сөннәтче бабай. Ул дини, әхлаклы, традицияләргә тугрылыклы, ата-бабалары рухын саклый, гаиләсен, балаларны ярата, авыл кешеләрен хөрмәт итә, дини традицияләрне җимерүчеләрне кабул итә алмый һ.б.**

4. Әсәрдә геройның эчке каршылыгы ни сәбәпле туа? Ул ничек чишелә? (5 балл). **Аның күңелендә каршылык Гөлйөземнең вафатыннан соң туа, Миңлесафа карчыкка өйләнгәннән соң, өйдәге тәртипнең үзгәрүенә, тормыштагы тәртипләрнең үзгәрүенә бәйле ул тирәнәя. Картның үлеме белән чишелә.**

5. Ни өчен әсәрдә икесе ике төрле холыкка ия ике татар хатыны образы кертелә дип уйлыйсыз? Алар аша автор нинди фикерләр үткәрә? (5 балл). **Автор әсәргә икесе ике төрле холыкка ия, дөньяга, традицияләргә, дини тәртипләргә карашлары да төрле булган Гөлйөзем һәм Миңлесафа образларын кертә. Алар аша әхлаклы, ирен зурлап торган хатын өйгә ямь бирә, ирен, гаиләсен бәхетле итә ала, татар хатыны шундый булырга тиеш дигән фикер үткәрә һ.б.**

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2019-2020 уку елы) 11 нче сыйныф

**Максималь балл – 50**

**IX. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (20 балл). Биремнәргә бер сүз һәм сүзтезмә белән җавап бирегез.**

33. Кискен конфликтка корылган, көчле рухлы геройларга ия драма жанры. **Трагедия**

34. Үзәгенә бәхетсез мәхәббәт, тарихи легендалар салынган, әкияти сурәтләү алымнарын яратып куллана торган лиро-эпик жанр. **Баллада**

35. Шигырь жанры караган әдәби төрнең атамасын язып куегыз. **Лирика, поэзия**

36. Шигырьдә тезмәләрнең охшаш тәмамлануы. **Рифма**

37. Чынбарлык вакыйгаларын сурәтләү аша совет системасы тәртипләрен, идеалларын җиткерүгә йөз тоткан әдәби агым. **Социалистик реализм**

38. Тормышны чынбарлыктагыча, барлык ваклыклары белән сурәтләргә омтылган иҗат юнәлеше. **Реализм**

39. Шигырьдә кулланылган, сөйләмнең гадәти булмаган тәртибенә нигезләнгән стилистик фигура. **Инверсия**

40. Әдәби әсәрдә герой күңелендә туган кичерешләрне тасвирлауны ачыклаган әдәби төшенчә. **Психологизм**

41. Әдәби әсәрдә геройның үз-үзе белән сөйләшүе. **Монолог**

42. XX гасыр татар поэзиясендәге төп шигырь системасы. **Силлабик**

**X. Әдәби әсәргә караган биремнәр (20 балл).**

5. Бу өзек кайсы әсәрдән? **“Матурлык”**

*Табигате белән үк ул, ничек дим, шундый тигез, сабыр холыклы бер егет иде. Ялагайлана да белмәс, масая да белмәс, яхшы белән яхшы, ә яман белән алыш-биреше юк, - андыйлардан үзен ничектер бөтенләй читтә тота белә иде...* (2 балл).

2. Бу әсәр кем тарафыннан, әдәбиятның кайсы чорында иҗат ителгән? (3 балл). **Ә.Еники тарафыннан, әдәбиятның 1960-80 нче еллар чорында иҗат ителә.**

3. Бу әсәрнең төп героена бәя бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (5 балл). **Бәдри – акыллы, тәрбияле, инсафлы, әхлаклы егет, гаиләсен, дусларын ярата, конфликтка керергә яратмый, әнисен искиткеч олылый белә, олыларга карата бик хөрмәтле. Эчке дөньясы белән идеаль герой итеп тасвирлана һ.б.**

4. Әсәрдә хикәяләүченең эчке каршылыгы ни сәбәпле туа? Ул ничек чишелә? (5 балл). **Әсәрдә хикәяләүченең эчке каршылыгы Бәдринең әнисенең тышкы ямьсезлеге белән Бәдринең аңа булган матур мөнәсәбәтен күргәч барлыкка килә. Ул бала белән әни кеше арасындагы матур мөнәсәбәтләрне күреп, матурлыкның күңелдә булырга тиешлеген аңлый.**

5. Әсәрдә скрипка образы нинди вазифа үти? (5 балл). **Бәдринең күңел матурлыгын, гаиләдәге матур мөнәсәбәтләрне, ана белән бала җылылыгын, рухи бөеклекне күрсәтү өчен кулланыла.**